**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**27.05.2019** **№ 766**

**2019 елда гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югары чиген билгеләү турында**

“Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында”, 2007 ел, 13 нче июль, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югары чиген билгеләү Методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының “2019 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданы буенча бер квадрат метр бәясе нормативы турында”, 2018 ел, 19 нчы декабрь, 821/пр номерлы Боерыгы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының “2019 елның 1 кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында”, 2018 ел, 19 нчы декабрь, 822/пр номерлы Боерыгы, Россия Федерациясе Торак Кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елга гражданнарны аз керемле дип тану өчен карар кабул итү өчен түбәндәге югары чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югары чиге:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 523 610 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 939 140 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 155 300 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420 сум;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 6 648 480 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган гомуми уртача айлык керемнең югары чик күләме күрсәткече, исәпләү нигезендә (1 нче кушымта) тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 12 837,83 сум;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 8 171,51 сум;
1.2.3. Өч яки аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 7 002,45 сум.

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторына, торак биналарда мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән югары чик күрсәткечләрен кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары Хәкимуллин Р.Ф.га йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

ТР Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
кушымта
27.05.2019 № 766

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югары чиген билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Социаль найм килешүе буенча муниципаль торак фондыннан торак биналар тәкъдим итү нормасы буенча торак биналар алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече түбәндәге формула белән исәпләнә (алга таба – исәпләү күрсәткече):

СЖ = НП х РС х РЦ, монда

СЖ - базар бәясен исәпләү күрсәткече яки милек бәясенең юагры чик бәясе;

НП - бер гаилә әгъзасына торак бина тәкъдим итү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән раслан торган торак бинаның бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе (2019 елның беренче кварталы өчен – 46 170 сум).

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

СЖ = 46 170  х 33 = 1 523 610 сум

б) ике кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 42 = 1 939 140 сум

в) өч кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 3 = 2 493 180 сум

г) дүрт кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 4 = 3 324 240 сум

д) биш кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 5 = 4 155 300 сум

е) алты кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 6 = 4 986 360 сум

ж) җиде кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 7 = 5 817 420 сум

3) сигез кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 46 170  х 18 х 8 = 6 648 480 сум.

2. Гражданинның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык гомуми керем күләменең югары чик күрсәткече:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$) / (0,3 х РС), монда

ПД - СЖ исәпләү бәясе буенча торак бина алу өчен агымдагы шартларда банктан ипотека кредитын алу өчен кирәкле, һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык гомуми керемнең югары чиге күрсәткече;

СЖ - социаль найм килешүе буенча торак бина тәкъдим итү нормасы буенча торак бина алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма), (Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы 7,75% елга, ягъни 7,75/100/12 айга =0,0065 айга);

КП - барлык кредит срогына кредит буенча гомуми түләүләр саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир суммасы бәйләнеше;

0,3 - кредит буенча түләүләрнең гаиләнең гомуми айлык керем белән бәйләнеше.

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының “2019 елның 1 кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында”, 2018 ел, 19 нчы декабрь, 822/пр номерлы Боерыгы белән торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Татарстан Республикасында 46 мең 170 сум дип билгеләнгән.

**Һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең югары чик күрсәткечен исәпләү**

1 нче таблица

| НП - торак бина нормасы (кв.м) | СЖ - торак бина алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак бинаның 1 кв.м.ның базар бәясе (сум) | ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы, % | КП – кредит буенча гомуми түләүләр саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир суммасы бәйләнеше | Кредит буенча түләүләрнең гомуми уртача айлык керем белән бәйләнеше | ПД- Керемнең чик күрсәткече (сум) (бер кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 46 170 | 7,75/100/12= 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 1523610 | 1 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 0,3 | 12837,83 |
| 42 | 1939140 | 2 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 0,6 | 8171,51 |
| 54 | 2493180 | 3 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 0,9 | 7002,45 |
| 72 | 3324240 | 4 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 1,2 | 7002,45 |
| 90 | 4155300 | 5 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 1,5 | 7002,45 |
| 108 | 4986360 | 6 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 1,8 | 7002,45 |
| 126 | 5817420 | 7 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 2,1 | 7002,45 |
| 144 | 6648480 | 8 | 46 170 | 0,65 | 180 | 0,7 | 2,4 | 7002,45 |